**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**
**«ӘҖМӘКӘЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»**
**МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**10 сентябрь 2026 ел** **№ 11/1**

# КАРАР

**«Әҗмәкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшыру хакында» 2013 елның 16 майдагы 34/5 номерлы карарга үзгәрешләр кертү турында**

«Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2022 елның 01 апрелендәге 90-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Әҗмәкәй авыл җирлеге Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. «Әҗмәкәй авыл җирлегендә муниципаль вазыйфаларны һәм муниципаль хезмәт вазыйфаларын биләүче затлар тарафыннан үз чыгымнары турында, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында белешмәләр тапшыру хакында» Комсомолец авыл җирлеге Советының 2013 елның 16 майдагы 34/5 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 1 нче кушымтаның 2 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Әлеге Федераль законның 2 статьясы 1 өлеше 1 пунктында күрсәтелгән вазыйфаларның берсен биләүче зат белешмәләр тапшыру елына кадәрге календарь ел дәвамында (алга таба - хисап чоры) җир кишәрлеге, башка күчемсез милек объекты, транспорт чарасы, кыйммәтле кәгазьләр (оешмаларның устав (җыелма) капиталларында катнашу өлеше, пайлар), цифрлы финанс активлары, цифрлы валюта сатып алу буенча һәр сделка буенча үз чыгымнары, шулай ук хатынының (иренең) һәм балигъ булмаган балаларының чыгымнары турында мәгълүмат, әгәр мондый килешүләрнең гомуми суммасы әлеге затның һәм аның хатынының (иренең) сатып алу килешүенә кадәрге соңгы өч елдагы гомуми кеременнән артып китсә, һәм башкарылган сделкага средстволар алу чыганаклары турында белешмәләр бирергә тиеш.».

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http:pravo.tatarstan.ru), рәсми сайтта (tukay.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Әҗмәкәй авыл җирлеге

Башкарма комитеты Җитәкчесе Г.Т. Хөсәинова